# 2015 ЕЛДА УЗАЧАК ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНАТЫ ВОЛОНТЕРЛАРЫ БУЛЫРГА 10 МЕҢНӘН АРТЫК КЕШЕ ТЕЛӘК БЕЛДЕРГӘН

28.10.2014, 15:26

ВОЛОНТ ЕРЛАР

**2015 елда Казанда узачак Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионатының рәсми сайтында волонтерлыкка кандидатлар өчен заявка 2014 елның 20 сентябреннән ачылды. Айдан артык вакыт эчендә дөньяның 43 иленнән 10 меңнән артык кеше халыкара ярышларны уңышлы уздыруда оештыру комитетына ярдәм итәргә теләк белдерделәр.**

Чемпионат ның волонт ерлык программасы федераль дәрәҗәдә т ормышка ашырылачак – оешт ыру комит ет ының коммерцияле булмаган парт нерлары арасында Россиянең 20 т өбәгеннән 26 министрлык, ведомст волар һәм югары уку йорт лары һәм Т ат арст ан Республикасының 11 парт нер-югары уку йорт лары бар. Парт нерларга урт ак т ырышлык белән мөһим бурычны үт әү – 2500 ирекле ярдәмчедән т орган команданы җәлеп ит ү, сайлап алу һәм әзерләү эше йөкләнгән. Т ат арст анны 2000 кеше т әкъдим ит әчәк, ә 500 кеше т өбәк делегацияләре сост авына керәчәк. Чит ил волонт ерларына да чемпионат т а кат нашу мөмкинлеге каралган - инглиз һәм рус т елен белгән, зур халыкара чараларда волонт ер булуда т әҗрибәләре булган яки булачак чараларның оешт ыру комит етларын т әкъдим ит үче кандидат лар волонт ер була алачаклар.

Заявка кампаниясе әле “экват ор”га җит еп кенә килсә дә, беренче волонт ерлык “рекорд”лары куелган да инде. Чемпионат т а волонт ер булырга т еләк белдергән иң яшь кандидат ка (Казаннан) бүген 11 генә яшь әле. Иң өлкән һәм т әҗрибәле кандидат исә 76 яшен т ут ырган һәм шулай ук Т ат арст ан башкаласын т әкъдим ит ә. Кандидат ларның урт ача яше исә – 21. Т өбәкләр дә рекордлар белән куандыра. Самара өлкәсе кандидат лар саны буенча абсолют лидер булды – т өбәкнең 550 вәкиле волонт ерлык өлкәсендә көчләрен сынап карамакчы. Санкт -Пет ербург т а да заявка кампаниясенең беренче ае зур күрсәт кечләр белән (451 заявка) узды, Мәскәүдә бу сан – 340, Свердловск өлкәсендә – 361, Волгоград өлкәсендә – 317, Удмурт иядә – 304. Чит ил волонт ерларыннан 200 заявка алынды, киләсе җәйгә Россиягә, яңа волонт ерлык т әҗрибәсе т уплар өчен, дөньяның 42 иленнән вәкилләр килергә планлашт ыра. Анкет аларның зур күпчелеге Казахст ан, Кыт ай, Испания, Ит алия, Белоруссиядән алынган.

Заявка бирү кандидат өчен беренче эт ап кына әле. 2014 елның 20 ноябреннән бөт ен ил буенча т өбәк-парт нерларда кандидат лар белән күпт ән көт елгән собеседованиеләр башланачак – махсус әзерләнгән рекрут ерлар т еләгәннәр белән сөйләшүләр уздырып, аларның компет ент лыгын, инглиз т елен белү дәрәҗәләрен т икшерәчәкләр. Собеседованиеләр 2015 елның апреленә кадәр барачак. Аннан соң волонт ерлар белән эшләү буенча менеджерлар корылмаларга командалар т уплау эшенә керешәчәкләр. Сайлап алынган кандидат ларны укыт у чират т агы эт ап булып т ора. Белем бирү программасы үз эченә чемпионат һәм волонт ерлык программасы т урында гомуми мәгълүмат ларны, волонт ерның шәхси компет енцияләрен үст ерүгә юнәлдерелгән күнекмәләрне, функциональ менеджерлар белән берлект ә билгеле бер юнәлеш буенча әзерлек башкарыла т орган функциональ т ренингны һәм булачак волонт ерлар үзләренең эш урыннарын һәм корылманың т өп зоналарын өйрәнә т орган т ренингны ала. Өйрәнү эшләре т әмамланганнан соң волонт ерлар аккредит ация һәм экипировка бирү урыныңа юл алалар, анда аларга үзенчәлекле экипировка, махсус т арифлы сим-карт а һәм чемпионат корылмаларына керер өчен аккредит ацияләнгән бейдж бирелә. Шулай ит еп оешт ыру комит ет ының ирекле ярдәмчеләре командасы 2015 елның июленә эшкә керешергә т улысынча әзер булачак.

Волонт ерлыкка кандидат лар анкет асы чемпионат сайт ында 2015 елның 1 гыйнварына кадәр ачык т орачак. Заявка бирергә һәм булачак су мундиалендә волонт ер булырга уйлаучыларның т агын ике ай вакыт лары бар. Кандидат лар инглиз т елен белү, командада эшли белү, коммуникабельлек, ст рессларга бирешмәү, акт ивлык һәм оешканлык сыйфат лары буенча сайлап алыналар.

Су спорт т өрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионат ы оешт ыру комит ет ы мат бугат хезмәт е

ЯҢАЛЫКЛАР Т АСМАСЫН АЧАРГА